Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«27» ноябрь, 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Калмаш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2020 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамы буенча күп фатирлы йортларда канализацияне реконструкцияләү проектын эшләү, экспертиза һәм материаллар сатып алу;
- З. Галиев урамы - Үзәк урамы– Яр Чаллы – Калмаш - Игенче автоюлы арасындагы юлга су аша үткәндә тимер киртә урнаштыру;
- Калмаш авылы юлларын ремонтлау;
- юлларны ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу, урам утларын урнаштыру, монтажлау

2. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында«авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Габдуллина